ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«18» сентябрь 2018 ел № 155

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Өлкәннәр декадасына әзерлек һәм аны үткәрү турында**

Өлкәннәр проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын аеруча җәлеп итү максатыннан, шулай ук халык арасында мәрхәмәтлек һәм кешелеклелек традицияләрен үстерү әһәмиятен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә**:

1. 2018 елның 1 октябреннән 10 октябренә кадәр халыкара өлкәннәр көне уңаеннан өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарга матди, социаль-көнкүреш, медик-социаль, психологик һәм башка төрле ярдәм күрсәтү максатыннан чаралар әзерләргә һәм үткәрергә.

2. Комиссия составын (1 нче кушымта) һәм Балтач муниципаль районының Өлкәннәр декадасына әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планын (2 нче кушымта) расларга.

3. Балтач муниципаль районы җирлекләрендә Өлкәннәр декадасына багышланган чараларны үткәрү буенча җаваплы затларны килешү нигезендә билгеләргә (3 нче кушымта).

4. Өлкәннәр декадасына әзерлек һәм аны үткәрү буенча җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген тәэмин итүне Балтач район башкарма комитетына йөкләргә.

5. Авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, район башкарма комитеты бүлекләре башлыкларына һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында социаль яклау территориаль органы җитәкчеләренә Өлкәннәр декадасын әзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашырга тәкъдим итәргә.

6. Авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, район башкарма комитеты бүлекләре башлыкларына 2018 елның 13 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә Халыкара өлкәннәр көнен үткәрү турында мәгълүматны бирергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы Р.Р.Нотфуллин